МӘГАРИФ

# ТУГАН ТЕЛ — ИЗГЕ ТЕЛ

Богырыслан шәһәрендә, татарлар күмәкләшеп яшәгән җирдә икенче санны урта мәктәп балаларга яңа бинада үзенең ишекләрен ачты. Татар краенда урнашкан тагы ике мәктәп аның филиаллары булып калдылар. Бу уку йортларында байтак татар балалары белем алалар.

Кызганычка каршы, бүгенге заманда яшь буыннар туган телендә яхшылап сөйләшергә кыенсыналар, ә грамоталы укый — яза белергә теләкләре бар.

Моңарчы күп еллар татар якшәмбе мәктәбе эшләп килде, балаларга анда туган телен, татар халкының тарихын, гореф — гадәтләрен, намаз тәртибен өйрәтергә тырыштык.

Әмма атна буена бер дә ял итмичә уку балаларга авырсызлык тудыра, шуңа күрә бу уку елында икенче урта мәктәптә һәм аның филиалларында гади уку көннәрендә этнографик филиаллары оештырырга булдык.

Бүгенге көндә татар балаларын туган телендә сөйләшергә, укырга, язарга, әдәпкә, гореф — гадәтләре белән таныштырырга мөгаллимәләр Хакимова Гәлимә — ханум, Вахитова Нурия — ханум тырышалар.

Үзем дә татар теленең грамматикасы һәм татар халкының тарихы белән яшьүсмерләрне таныштырам. Шәһәребезнең “Туган тел” исемендәге татар иҗтимагый үзәгенең рәисе Хәмзә Газизов, шәһәр советының депутатлары Дамир Туматов, Фәрит Садретдинов, Илдар Тазетдинов бу изге эшкә зур ярдәмнәрен күрсәтәләр.

Мәктәпнең завучлары Камалтдинова Әлфинур, Рахматуллина Зинира татар балаларына үз телләрен, гореф — гадәтләрен белүе кирәклеген төшендерәләр, төрле милли чаралар үткәрәләр. Г.Тукай исемендәге мәдәният йортындагы китапханәче Гөлфия Латыйпова шул чараларны уздырырга булыша.

Мәктәпнең беренче һәм өченче корпусында музейлар урнашты, анда татар халкының милли киемнәре, көнкүренештә кулланылган торган әйберләре белән балаларны таныштырабыз.

Элек татарлар өендә хуҗаларга өстәл һәм караваты урынына сәке булган.



Шундый бер татар өенең почмагын икенче мәктәпнең музеенда (Победная урамында) күрергә мөмкин (**фотода**).

Татар иҗтимагый үзәгенең, укытучыларының татар телен саклап калу, яңа буыннарга туган телгә мәхәббәт иңдерү, милли гореф — гадәтләрен көнкүреш тормышына кертү — иң теләгән максаты булып тора.

**Марат ЗАКИРОВ,**
**Богырыслан ТИҮ**
**“Туган тел”**
**вәкиле.**

КНИЖНЫЕ НОВИНКИ

# О БУГУРУСЛАНЕ НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ



**В третьем номере нашей газеты, мы уже рассказывали об этой книге. Сегодня, по просьбе читателей и с согласия автора М.Г.Закирова, публикуем очередной отрывок из книги о Бугуруслане.**

Богырыслан — уезд шәһәре.

Екатерина-патша аның белән генә канәгатьләнмәде, ул Ырымбур губерниясен тар-мар итергә уйлады, аны Уфа наместлигына катыштырды. Аның Указы 1781 елның 23 декаберендә раслана. Ул Указда Богырыслан шәһәре барлыкка килгәне турында сүз бара, шуның өчен Указны рус телендә китерәм:

*«Всемилостивейше повелеваемъ нашему генералу-поручику правящему должность Генерала-губернатора Уфимского и Симбирского Якоби в апреле наступающего 1782-го года исполнить по учреждениямъ нашим отъ 7-го ноября 1775-го года въ наместничестве Уфимскомъ составя оное из двухъ областей Уфимской и Оренбургской, изъ коихъ къ первой принадлежать будутъ восемь уездов а именно: Уфимскій, Бирскій, Мензелинскій, Бугулминскій, Бугурусланскій, Белебеевскій, Стерлита-мацкій, да Челябинскій, которыи отделить отъ Пермскаго наместничества, къ Оренбургской же области четыре уезда Оренбургскій, Верхноуральскій, Бузулуцкій и Сергіевскій въ следствіе чего пригороды и селенія по коимъ названы уезды переименовать уездными городами».*

*Екатерина*
*въ Санктпетербурге*
*декабря 23дня 1781года.*

Богырыслан уезды бик зур булган, ул элеке җиде район җирен алып торган. Әсәкәй, Абдулино, Матвеевка, Пономаревка, Северный, Похвистнево районнары уездка кергән.

Шушы Указ буенча 23 декабрьда 1781 елда Богырыслан уезд шәһәре барлыкка килә. Икенче 1782 елны Богырыслан шәһәренең гербы да раслана. Ул гербта ике хайван рәсеме төшерелгән була: өстендә — сусар, астында — кара сарык. Ул бу тирәдә аулык хайваннар барлыгын һәм халыкның маллар үстерүен билгели.

1891- нче елда Санкт — Петербургта Брокгауз һәм Ефрон редакциясе буенча басылып чыккан энциклопедиянең 4 томын алсак, анда Богырыслан шәһәре турында болай язган:

“Богырыслан шәһәрендә 18476 кеше торган; шулар арасында 11801 христианнар, 1280 мөселманнар яшәгәннәр. Халык иген, бакча яшелчәләре, җиләк — җимеш үстереп шөгыльләнгәннәр, умарталар тотканнар, күбесе сәүдә иткәннәр. Сәүдә эшләре бик уңышлы барган. Шәһәрдә ел да ике мәртәбә шаулап ярминкә үткән. Яз көннәрендә — унынчы җомга көннән башлап бер атнага сузылган. Көз көннәрендә — беренче сентябрьдан башланып бер атнага якын барган”.

Ярминкәләр бик кызык үткәннәр. Богырысланга зур шәһәрләрдән дә сәүдәгәр байлар килгәннәр. Уфадан, Казаннан, Самарадан, Ырымбурдан — кайдан гына җыелмаганнар. Шәһәрдәге бай сәүдәгәрләр дә үзләренең ерактан алып кайткан товарларын ярминкәгә чыгарганнар. Шәһәрдәге иң бай сәүдәгәр Фадеев Сергей Александрович Германиядән алып кайткан “Зингер” дигән тегү машинасы белән мактанган. Аның яшәгән бинасы шәһәрнең уртасында иң зур, ике этажлы өйдә урнашкан. Беренче этажында кондитер кибете ачкан, икенче этажында гаиләсе белән торган. Бу архитектура бизәкләре белән эшләнгән бина әлегә кадәр сакланып килгән. Хәзер анда балалар сәнгать мәктәбе урнашкан.

Әлек Фадеев шәһәрдәге байларны чакырып баллар үткәргән. Бу бал бинаның икенче этажындагы иң зур, бизәкләнгән залында үткән. Кунакларга төрле ашамлыклар подвалдан икенче этажга күтәргеч механизмнар җиткергән. Биредә шәһәр байлары Шуваловлар, Агеевлар, Хохловлар, Печерскийлар ашап — эчеп, карта уйнап, биеп, шат күңеллелек белән вакытларын үткәргәннәр.

Ярминкә вакытларында Фадеев балконга чыгып, урамда җыелган яланаяклы крестьян балаларына конфетлар, прәникләр, чикләвекләр ыргыткан, ә ир — атларга мичкәләрдән кызыл аракы эчергән. Шулай үзенең байлыгын күрсәтә торган булган. Малайлары да ярминкәләрдә ат чабышларында катнашканнар. Шувалов малайлары белән ярышып, кәсепчеләр сатарга чыгарган чүлмәкләрен чыбыркы белән ватканнар.Кем күбрәк вата, шул җиңә, ә оттырганнары тилмереп — елап торган кәсепчеләрнең битләренә берничә сум акча ыргытканнар, йөгерештә катнашып хәлсезләнгән атларның авызларыннын күбекләр килә башлагач, аларны шампанскилар эчереп хәлгә керткәннәр.

Тирә яктан килгән крестьяннар үзләре үстергән иген, яшелчә, ит, май, сөт белән сату иткәннәр. Шулай итеп әз булса да үзләренең авыр тормышларын җиңеләйтергә тырышканнар.

Фадеевның гаиләсе зур булган, аның үнбер баласы да үзләренең тормышларын корып, байлык чәчеп, күңел ачып яшәгәннәр. Кызлары хатын — кызлар гимназиясендә укыганнар, җитә баргач, үзләренә бай егетләргә кияүгә чыгу турында хыялганнар. Әмма ләкин байларның ничек кенә уңышлы тормышлары барса да, алар бәла — казадан котылып яши алмаганнар. Серафима исемле кызлары бер чибәр ярлы егеткә гашыйк булган. Бу егетнең ярлы гаиләдән чыккан, бигрәк тә татар икәнен белгәч, ата — анасы аңа рөхсәт бирмәгәннәр, малайларына кыз артыннан күзләргә кушканнар. Һаман да яшьләр яшертен генә очрашсалар да, бу хәл аталарына җиткерелгән. Атасы Серафиманы биктә тотарга әмер биргән. Кыз моңа чыдый алмыйча, кайчандыр абыйсы бүләк иткән пистолеттан атылып үлгән.

Икенче бай сәүдәгәр Шувалов Кинәле буендагы зур, ике этажлы бинада яшәгән. Ул аскы этажында банк ачкан, Кинәле елгасында буа ясаган, су тегермәне ачкан. Шувалов тегермәненең югары сортлы бодай оны бөтен тирә якта данлыклы дип саналган.

Соңыннан инде, байлар куылгач, тегермәннәрен Совет Хөкүмәте алгач, ул өченче тегермәне Шаһеттин тегермәне дип халык белә иде, чөнки ул да данлы тегермәнче булган.

Ә Нәҗагай елгасында тагын бер, дүртенче тегермәне бар иде, аны Барый тегермәне дип халык йорткән.